2025 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кама-Исмәгыйль авылы җирлеге Кама-Исмәгыйль авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

22 ноябрь 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кама-Исмәгыйль авыл җирлегенең Кама-Исмәгыйль авылында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кама-Исмәгыйль авыл җирлегенең Кама-Исмәгыйль авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 600 сум күләмендә үзара салым кертергә,Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү торбаларын алмаштыру, задвижкалар урнаштыру, коелар урнаштыру).

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Кама-Исмәгыйль авылы, Ленин урамы, 92а йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кама-Исмәгыйль авыл җирлеге башлыгы А.З.Шайдуллина

Татарстан Республикасы муниципальное образование «Кама-Исмагиловское сельское поселение» Альметьевского муниципального района
ОГРН 1021601628465
Р05-10960/16
КАМА-ИСМАГИЛОВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ СОВЕТ
ИНН 1607002226
КПП 164401001